РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

08.11.2021 — № 1290-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 23 гыйнварындагы 64-п номерлы карары белән расланган “2017-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” муниципаль Программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү” дәүләт программасын раслау турында” 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** “2017-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” муниципаль программасын раслау турында” Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 23 гыйнварындагы 64-п номерлы карары белән расланган, “2017-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” муниципаль программасына (Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 13 июлендәге 1046-п номерлы, 2019 елның 4 декабрендәге 1664-п номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр редакциясендә) (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** Программага 1 кушымтада “2017-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү Кагыйдәләренә түбәндәге эчтәлекле 32 пункт өстәргә:

“32. Сатып алына торган торак бүлмә (шул исәптән өлешле төзелеш объекты) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан яисә торак йорт төзелеше Татарстан Республикасы территориясендә алып барылырга тиеш”.

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

**3.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы И.Р. Гариповка йөкләргә.

Җитәкче — М.Р. Ишниязов